# БӘБКӘЛӘР

Көне буе суда алар,
Йөзәләр дә чумалар.
Балык тоткан булалар.
Үлән йоткан булалар.

*Кушымта (2 тапкыр):*
Бик матур тезелешеп,
– Пип-пип, пип-пип! – килешеп,
Бәбкәләр күлгә килә,
Су яратканга күрә.

Һаман шулай уйныйлар,
Судан бер дә туймыйлар.
Чисталыкны яраталар,
Шуңа тиз үсә алар...

*Кушымта (2 тапкыр).*